ПӘНҖЕШӘМБЕ
7
ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 5 (6727)
Аерым номеры 20 тиен.

Барлык илләренең пролетарийлары, берләшегез!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

СОҢГЫ СӘГАТЬТӘ

Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләрнең трофейлары һәм дошманның югалтулары

943 нче елның 1 нче гыйнвареннан 5 енә кадәр СТАЛИНГРАДТАН ньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак немец-фашист басып алучыларга ршы сугышларда безнең гаскәрләр түбәндәге трофейларны КУЛГА ӨШЕРДЕЛӘР: 27 самолет, 56 танк; 429 пулемет, 267 миномет, танкка ршы ата торган 1.016 мылтык; 10.000 автомат, 15.770 винтовка; 00.000 нан артык снаряд, 20.000.000 нан артык патрон, 500.000 нән тык авиабомба, 83 радиостанция, сугыш припаслары һәм азык төялгән 239 автомашина, 3.217 ат; сугыш йөкләре төялгән 4.400 повозка; паровоз; 400 вагон, һәртөрле 37 склад.

Дошманның 6.500 солдаты һәм офицеры плен алынды, ә 1942 нче лның 19 нчы ноябреннан башлап элек плен алынганнар белән берлектә знең гаскәрләр барлыгы 144.150 дошман солдатын һәм офицерын ен алдылар.

1943 нче елның 1 нче январеннан 5 енә кадәр булган вакыт эчендә ошманның 88 самолеты, 118 танкысы, төрле калибрлардагы 122 оручесе, 291 минометы; 787 пулеметы; гаскәрләр һәм сугыш йөкләре өялгән 570 автомашинасы, 340 мотоциклы; 432 вагоны; һәртөрле 20 лады ЮК ИТЕЛДЕ.

1943 нче елның 1 нче январеннан 5 енә кадәр булган вакыт эчендә ошманның 20.000 нән артык солдат һәм офицерлары үтерелде.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

МОСКВА, КРЕМЛЬ ИПТӘШ СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Бөек Октябрь Социалистик Революциясенең 25 еллыгына карата Сезең докладыгыз һәм приказыгыз белән, шулай ук совет гаскәрләренең немец-фашист бандаларга каршы уңышлы һөҗүме белән рухланган Советлар Союзы комсомолецлары һәм яшьләре героик Кызыл Армиябез өчен кораллар ясауга акча җыюда актив катнашалар.

36 өлкәдә Кызыл Армия өчен кораллар төзелешенә комсомолецлар әм яшьләр 181.657.428 сум акча керттеләр.

Акча җыюда пионерлар һәм мәктәп балалары актив катнаша. Рязань лкәсендә Муравлян районындагы 3 мәктәпнең укучылары колхозларда шләп алган акчаларыннан танклар төзелешенә 300.000 сум; Спас райны, Кутуков мәктәбенең пионерлар дружинасы 25.000 сум акча һәм 25 пот ашлык керттеләр. Москва өлкәсе, Сухаревка мәктәбендә укуылар үзләренең колхозда эшләп алган акчаларыннан «Пионер» исемле анклар колоннасы төзелешенә 15.000 сум, Москва шәһәренең Ленин айонындагы 639 нчы мәктәпнең укучылары 9.385 сум керттеләр. Красноярск крае, Советск районының Березовка авылындагы урта мәктәпнең нче класс укучысы пионерка Галя Горестова «Пионер» исемле танклар колоннасы төзелеше өчен Дәүләт банкысына 8.000 сум кертте. Красноярск краенда пионерлар һәм мәктәп балалары барлыгы 100.000 сумнан артык җыйдылар.

Куйбышев өлкәсе, Сурск урта мәктәбенең 6 нчы классында укучы пионерка Таня Чекулаева Дәүләт банкысына 9.000 сум кертте. Таня 3 яшендә, өйдәге бөтен эш аның җилкәсендә. Таняның 3 абыйсы фронтта, шулардан икесе орденлылар. Таня болай дип яза:

«Мин үзем эшләп тапкан һәм сугыш машиналары төзелешенә бирелән һәрбер тиеннең гитлерчы кабахәтләрне тизрәк тар мар итүдә һәм өнаһсыз балаларның күз яшьләре һәм каннары өчен рәхимсез үч алуда уганыбыз Кызыл Армиягә булышлык итүен телим».

Авыл комсомолецлары һәм яшьләре, акча җыюдан тыш тагын Кызыл Армия фондына продуктлар җыю эшенә дә керештеләр. Сезнең, иптәш Сталин, Омск өлкәсе комсомолецларына һәм яшьләренә биргән җавабыыздан соң бу өлкәдә 15.000 пот ашлык җыелды. Рязань өлкәсе комсомолецлары һәм яшьләре 7.200 пот ашлык җыйдылар.

Комсомолецлар һәм яшьләр совет партизаннары өчен бүләкләр җыюны башлап җибәрделәр. Партизан отрядларына 9.500 данә тышкы кием, 9.250 пар эчке кием, 2.050 пар аяк киеме, 8.477 метр мануфактура, 1.500 аптечка, 7.000 пачка тәмәке, 5.500 кисәк сабын, 102 радиоприемник, 25 радиостанция җибәрелде. Шуның өстенә партизаннарга 102.905 данә төрле бүләкләр җибәрелде. Болар арасында урын-җир әйберләре, әйбер сала торган капчыклар, салкын кораллар, котелоклар; флягалар, баш киемнәре, җепләр, туену продуктлары һәм башка әйберләр бар.

Яңа елга карата комсомолецлар һәм яшьләр партизаннарга яңа ел бүләкләре итеп 6.500 данә тышкы кием; 450 пар аяк киеме, сохари, май, казылык; кондитер әйберләре, консервалар, 150 пот бал, 3.000 пачка тәмәке җибәрделәр. 22.500 данә төрле әйберләр җибәрелде. Болар арасында яулыклар; җылы киемнәр, җепләр, бритвалар, портсигарлар һ. б. бар.

Үзләрен аеруча күрсәткән партизаннарга комсомолецлар һәм яшьләр исемле бүләкләр җибәрделәр. Шулар арасында 104 данә алтын һәм көмеш сәгатьләр, 68 портсигар, 400 фин пычагы бар.

Кызыл Армия фондына акча һәм продуктлар җыю дәвам итә һәм һәркайда да зур патриотизм эше сыйфатында үтә.

Совет халкы алдына Сез куйган максатны үтәү өчен—совет җирен немец-фашист кабахәтләрдән азат итү, Ватаныбызның намусын, азатлыгын, бәйсезлеген саклап калу өчен Советлар Союзы комсомолецлары һәм яшьләре бөтенесен эшләргә әзер торалар.

ВЛКСМ Үзәк Комитеты Секретаре Н. МИХАЙЛОВ.



Казан кошчылык комбинаты фронтка йөз меңнәрчә данә меланже, һәртөрле көш итләре җибәрә. Рәсемдә: комбинатның стахановчыларыннан В. П. Семенова, М. С. Сәйфетдинова иптәшләр әзер продукцияне тартмаларга тутыралар.

Б. Невзоров фотосы.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ 25 ЕЛЛЫГЫ ХӨРМӘТЕНӘ БӨТЕНСОЮЗ СОЦИАЛИСТИК ЯРЫШЫН ТАГЫН ДА КИҢРӘК ҖӘЕЛДЕРИК!

МОСКВА, КРЕМЛЬ,

Дәүләт Оборона Комитеты Председателе Иосиф Виссарионович СТАЛИНГА

Кадерле Иосиф Виссарионович!

Кораллар Халык Комиссариаты карамагындагы 172 нче номерлы, Молотов исемендәге заводның эшчеләр, инженер техник работниклар һәм хезмәткәрләр коллективы, корал җитештерүчеләр ярышының инициаторы буларак, дәүләт планнарын һәм үз йөкләмәләрен Бөтенсоюз социалистик ярышының беренче көннәреннән алып ук арттырып үтәп килә. Ел ахырында, январь ае белән чагыштырганда; пушкалар эшләп чыгаруны без ике тапкыр арттырдык. Сугышка кадәрге чор белән чагыштырганда пушкалар эшләп чыгару 10 тапкырдан күбрәккә артты. Дәүләт Оборона Комитетының артиллерия буенча заданиеләре арттырып үтәлде һәм планнан тыш 40 полк кораллар белән тәэмин ителде. Продукциянең үзенә төшү бәясе 27 процентка киметелде. Эшчеләрнең рационализация тәкъдимнәрен тормышка ашыру нәтиҗәсендә 22,4 миллион сумлык экономия ясалды. Заводның рентабельлеге бер ел эчендә 42 миллион сум булды. Завод коллективы, ВКП(б) Үзәк Комитетының Кызыл Байрагын 4 ай буе рәттән яулап алып, югары данга иреште. Сезнең докладыгыз һәм приказыгыз белән, шулай ук Кызыл Армиябезнең героик һөҗүмнәре белән рухланып, заводның эшчеләре һәм хезмәткәрләре 1943 нче елда фронт өчен коралларны тагын да күбрәк бирүне үз алларына бурыч итеп куялар. Без, илебезнең барлык предприятиеләренә мөрәҗәгать итеп, Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә Бөтенсоюз социалистик ярышын тагын да киңрәк җәелдерергә чакырабыз һәм планнан тыш 10 полкны кораллар белән тәэмин итәргә йөкләмә алабыз. Без Сезгә, кадерле Иосиф Виссарионович, сүз бирәбез: дошманны тизрәк тар мар итү өчен оборона продукциясен тагын да күбрәк бирүдә көчебезне һәм вакытыбызны аямабыз.

Завод коллективы тапшыруы буенча:

Завод директоры—Быховский,
ВКП(б) райкомы секретаре—Кушневский,
ВКП(б) Үзәк Комитеты парторгы—Сюндюков,
Завком председателе—Шестопалов,
ВЛКСМ Үзәк Комитеты комсоргы—Попов,
завод стахановчылары—Галанин, Гилев; Зырянов, Соснин; Багаева.

БЕР СМЕНАГА 1.112 ПРОЦЕНТ

Завод газетасы «Молния» күренекле рекорд куелу турында хәбәр итте. Стахановчы Сәфәр Һидиятуллин хезмәт җитештерүчәнлеген моңа кадәр күрелмәгән югарылыкка күтәреп, смена заданиесен 1.112 процентка үтәде.

Иптәш Һидиятуллин бу гүзәл күрсәткечкә ничек ирешә соң? Аңа бер ашыгыч задание өчен калайдан озынча кисәкләр ясау эше тапшырылды. Ул үз агрегатының бөтен көчен максималь рәвештә файдаланырга булды һәм моның өчен 2 миллиметрлы 10 калайны берсе өстенә берсен өеп, механик кайчылар белән кисте. Кискәндә аларны кисеп торырга җайланма ясады һәм бу җайланма бер үк вакытта шаблон булып та хезмәт итте.

Шулай итеп, һәрбер кисәкне үлчәмәү һәм кисү санын күп тапкырга киметү нәтиҗәсендә иптәш Һидиятуллин хезмәт җитештерүчәнлегенең югары үрләгән бирүгә һәм смена заданиесен 1.112 процентка үтәүгә ирешә.

Эштә гади җайланма кертүдә участок мастеры иптәш Сидоренко һәм эш урынына материалны үз вакытында китереп торуда эшче Хәйруллин яңа мең процентчыга зур булышлык күрсәттеләр.

Иптәш Һидиятуллин үзенең бу рекордын Кызыл Армиянең фронтта немец-фашист гаскәрләргә каршы яңа ударларына багышлый.

М. ШВАРЦЕР.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

6 нчы ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

6 нчы январьга каршы төндә безнең гаскәрләр Донның урта агымы районында, Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак, Үзәк фронтта һәм Төньяк Кавказда элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр дошман позицияләренә артиллериядән атып тордылар. Заводлар районында дошманның 12 ДЗОТ ы һәм блиндажы җимертелде. Сталинградтан көнбатыштарак ике биеклек өчен булган сугышта безнең сугышчылар дошманның берничә дистә окопын алдылар. Сугыш кырында 200 дән артык немец солдатларының һәм офицерларының үле гәүдәләре калды. Пленныйлар алынды һәм трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр. Күп кенә участокларга дошман яңа частьлар китерде. Гитлерчыларның, контратакалар ясап, совет гаскәрләренең һөҗүмен тоткарларга маташулары һәрвакыт уңышсызлыкка очрый. Командиры кече лейтенант Василенко булган гвардияче пехота подразделениесенә дошманның 14 танкысы контратака ясаган иде. Сугышчылар һәм командирлар дошман танкларын танкка каршы ата торган мылтыклар уты белән каршыладылар. Озак та үтми немецларның 5 танкысына ут капты, ә калганнары кире борылып китте. Атака кире кайтарылды. Икенче бер участокта Н-че часть халык яши торган бер пункт өчен булган сугышларда 400 дән артык гитлерчыны юк итте, 9 орудие, 300 винтовка, бер сугыш припаслары склады кулга төшерде. Шулай ук немецлар тарафыннан совет гражданнарыннан талап алынган 3.000 центнер ашлык һәм күп кенә мөгезле терлекләр кулга төшерелде.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че берләшмә дошманга каршы сугышларда немецларның 6 р батальонга якын пехотасын, 3 танкысын, 2 бронемашинасын, 11 орудиесен, шулардан 5 зенит орудиесен юк итте. 100 дән артык пленныйлар алынды. Икенче бер участокта совет гаскәрләре тарафыннан чолганып алынган бер немец гарнизонына үтәргә маташкан дошман танкларының һәм пехотасының атакасы кире кайтарылды. 180 гитлерчы һәм 6 танк юк ителде.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп пунктларны алдылар. Н-че берләшмә сугышчылары сугышларның ике көне эчендә немецларның 3 моторлы бер транспорт самолетын, 26 танкысын, 29 орудиесен, 33 минометын, күп кенә автомашиналарын, кул коралларын һәм төрле хәрби милекләрен кулга төшерделәр. 300 дән артык немец солдатлары һәм офицерлары плен алынды.

* * *

Украина партизаннарының бер отряды фашистларның бер волость идарәсен тар-мар иткән һәм халык яши торган пунктта немецлар гарнизонын кырып ташлаган. 25 винтовка кулга төшерелгән. Партизаннар немецлардан Германиягә озату өчен әзерләп куелган берничә мең пот ашлыкны сугышып алганнар. Совет патриотлары ашлыкны халыкка өләшеп биргәннәр.

* * *

Румыниянең күп кенә шәһәрләрендә сугышка каршы демонстрацияләр булган. Крайово шәһәрендә демонстрантлар сугышны туктатуны һәм Гитлер Германиясе белән элемтәне өзүне таләп иткәннәр. Бухарестта хәрби министрлык бинасы янында үзләренең Россиядәге якын кешеләренең язмышы турында берәр нәрсә белү өчен килгән йөзләрчә кешеләр көн саен җыелып торалар. Румыния газеталары Совет—Германия фронтында Румыния гаскәрләренең җиңелүе турында бернәрсә дә дәшмиләр, ләкин башкала һәм бүтән шәһәрләрнең халкы моны инде белә. Сигуранца тарафыннан җибәрелгән яшерен циркулярда жандармериягә «фронттагы хәл турында һәртөрле сөйләнүләрне һәм дискуссияләрне» бастырырга тәкъдим ителә. Циркулярда болай диелгән: «Хәзерге шартларда безнең фронттагы уңышсызлыкларыбыз турында сөйләүче һәрбер кешене, җиңелүне яклаучы дип карап, хәрби трибунал судына бирергә кирәк, чөнки андый кешеләр безгә һәлакәт һәм кабер әзерлиләр». Соңгы ике атнада Бухарестта җиңелүне яклауда гаепләнеп йөзләрчә хатын-кызлар кулга алынган. Шулай ук законсыз рәвештә корал саклаган өчен күп эшчеләр һәм студентлар кулга алынганнар.

6 нчы ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

6 нчы январьда безнең гаскәрләр Донның урта агымы районында һөҗүмне дәвам иттереп, халык яши торган пунктлардан Каргальско-Белянскийны, Вербовскийны, Мариинскаяны, Холодныйны, Камышевскаяны, Ясыревны, Зур Орловканы, Чертковскаяны алдылар.

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр халык яши торган пунктлардан Ново-Осетиновскаяны, Красноградскаяны, Урожайноены, Матвеевскийны, Кызборын 1 нчене, Кызборын 2 нчене, Кызборын 3 нчене, Баксанны, Старая Крепостьны, Карагачны, Константиновскаяны, Курскаяны, Кановаяны, һәм тимер юл станцияләреннән Аполонскаяны һәм Солдатскаяны алдылар.

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә сугышлар алып бардылар.

* * *

5 нче январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 10 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 70 кә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 10 артиллерия батареясының утын бастырдылар, 2 сугыш припаслары складын шартлаттылар, бер батальонга якын дошман пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинградның заводлар районында безнең частьлар, вак штурм группалары булып хәрәкәт итеп, дошманның 23 блиндажын җимерделәр һәм алардагы гитлерчыларны юк иттеләр. Сталинградтан көнбатыштарак бер биеклек өчен сугышлар дәвам итә. Дошман бик нык каршылык күрсәтә, ләкин безнең подразделениеләр алга киттеләр һәм 70 окопны алдылар. 400 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Безнең сугышчылар 10 станоклы пулемет, 18 кул пулеметы, 11 автомат, 285 винтовка, танкка каршы ата торган 2 мылтык, бер радиостанция һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

Безнең очучылар аэродромнарда немецларның 3 транспорт самолетын юк иттеләр. Һава сугышларында дошманның 9 самолеты бәреп төшерелде.

* * *

Сталинградтан көньяк-көнбатыштарак һәм көньяктарак безнең гаскәрләр, дошманның каршылыгын җиңеп, һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Гитлерчылар бер уңайлы оборона чигеннән бәреп чыгарылдылар һәм зур югалтуларга дучар ителделәр. Н че берләшмә сугышчылары соңгы сугышларда немецларның 6 танкысын, 85 автомашинасын, 3 тракторын, 32 пулеметын, 2.000 авиабомбасын, 3.000 снарядын, танкка каршы ата торган күп мылтыкларын, автоматларын, винтовкаларын һәм башка трофейлар кулга төшерделәр.

* * *

Донның урта агымы районында безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм көчләрнең бер өлеше белән дошманның чолганып алынган гарнизоннарын юк итү сугышлары алып бардылар. Н-че часть танкистлары сугыша-сугыша алга киттеләр һәм немецларны халык яши торган, көчле рәвештә ныгытылган пункттан бәреп чыгардылар. Бу сугышларда 300 немец солдаты һәм офицеры кырып ташланды, дошманның 3 танкысы зарарланды һәм 18 автомашинасы юк ителде. 4 орудие, 13 пулемет, танкка каршы ата торган 22 мылтык һәм элемтә милекләре склады кулга төшерелде.

* * *

Үзәк фронтта безнең гаскәрләр үзләре алган позицияләрне ныгыттылар һәм аерым участокларда дошманның контратакаларын кире кайтардылар. Великие Лукидан көньяк көнбатыштарак иптәш Иванов командалыгындагы гвардеецлар гитлерчыларны халык яши торган бер пункттан бәреп чыгардылар. Немецлар, элекке хәлне кайтарырга омтылып, контратакага пехота һәм бер группа танклар җибәрделәр. Ике сәгать буена бик каты сугышканнан соң дошман алып ташланды. Дошманның 150 солдаты һәм офицеры юк ителде, 3 танкысы яндырылды.

* * *

Төньяк Кавказда совет гаскәрләре, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга киттеләр һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Халык яши торган бер пункт өчен булган сугышта Н че часть 200 дән артык дошман солдатларын һәм офицерларын юк итте. 12 танк, 25 пулемет, 2 орудие, 60 мотоцикл, күп кенә сугыш припаслары һәм кул кораллары кулга төшерелде. 66 кеше плен алынды. Зенит артиллериясе уты белән немецларның 4 самолеты атып төшерелде һәм 4 самолеты зарарланды.

* * *

Ленинград партизаннарының бер отряды немецларның халык яши торган бер пункттагы гарнизонына кинәт һөҗүм ясаган. Совет патриотлары 35 гитлерчыны кырганнар һәм үз базаларына китә башлаганнар. Партизаннар артыннан немецлар зур җәза отряды җибәргәннәр. Партизаннар, оста маневр ясап, карательләрне немецлар подразделениесе урнашкан күрше авылга таба җибәргән. Бу пунктта булган немец солдатлары, карательләрне партизаннар дип белеп, ут ачканнар. Гитлерчылар арасында сугыш башланган. Нәтиҗәдә ике яктан 60 кеше үтерелгән.

* * *

Советлар Украинасының Кременчуг шәһәрен немец-фашист кабахәтләр төрмәләр шәһәренә әйләндергәннәр. Монда немецлар тирә-як авыллардан һәм местечколардан меңнәрчә совет гражданнарын куып китерәләр. Аларны Германиянең хәрби властьлары приказларына саботаж ясауда гаеплиләр. Монда, Кременчуг махорка фабрикасының киптерү сарае районында гитлерчы палачлар кулга алынган кешеләрне ерткыч төстә газаплыйлар, ә соңыннан үтерәләр. Бик үк тулы булмаган саннарга караганда, фашист ерткычлар декабрь аенда Кременчугта 2.000 нән артык совет гражданнарын атып үтергәннәр.

ХӘРӘКӘТТӘГЕ АРМИЯ (Үзәк фронт). Күптән түгел сержант М. П: Юдинның расчеты дошманның 5 ут точкасын бастырды һәм бер взвод немец автомат икларын кырып ташлады. Рәсемдә: иптәш Юдин сугышчылары яңа позицияләргә урнашалар.

ТАСС фотохроникасы.

Австралия, Бельгия, Голландия, Греция, Һиндстан, Канада, Кытай, Люксембург, Яңа Зеландия, Норвегия, Польша, Америка Кушма Штатлары, Бөек Британия һәм Төньяк Ирландия Берләшкән Королевствосы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Чех-Словакия республикасы, Югославия, Көньяк Африка Союзы хөкүмәтләренең һәм Франция милли комитетының декларациясе

Австралия, Бельгия, Голландия, Греция, Һиндстан, Канада, Кытай, Люксембург, Яңа Зеландия, Норвегия, Польша, Америка Кушма Штатлары, Бөек Британия һәм Төньяк Ирландия Берләшкән Королевствосы, Совет Социалистик Республикалар Союзы, Чех-Словакия республикасы, Югославия, Көньяк Африка Союзы хөкүмәтләре һәм Франция милли комитеты, һичбер сәбәпсезгә һөҗүм ясалган һәм таланган илләрне һәм халыкларны милектән мәхрүм итү буенча үзләре белән сугыш хәлендә булган хөкүмәтләр тарафыннан кулланыла торган методларны бетерү өчен мөмкин булганның бөтенесен эшләргә уйлаулары турында, белергә тиеш булган барлык кешеләргә һәм бигрәк тә битараф илләр гражданнарына шушының белән рәсми кисәтү ясыйлар. Шушы нигездә, шушы декларация белән чыгучы, югарыда әйтелгән хөкүмәтләр һәм Франция милли комитеты үзләре белән сугыш хәлендә булган хөкүмәтләрнең оккупацияләнгән яки турыдан-туры яисә читләтеп контроль астына алынган территорияләрдәге яки моннан элек бу территорияләрдә булган, шул территорияләрдә яшәгән кешеләрнең, шул исәптән юридик шәхесләрнең дә, нинди генә характерда булса да, милекләрен, хокукларын һәм интересларын башкаларга тапшыруларын да яки нинди генә алыш-биреш итүләрен дә юкка чыккан дип игълан итү хокукын тулысынча үз карамакларында калдыралар.

Мондый тапшыру яки алыш-биреш итү ачыктан ачык талау формасында булганмы, яисә тыштан караганда законлы формага кертелгәнме, хәтта мондый алыш-биреш итү яки тапшыру гүяки ирекле характерга нигезләнгән булса да, боларның берсенә дә карамастан бу кисәтү үзенең көчен саклап кала.

Бу декларация белән чыгучы хөкүмәтләр һәм Франция милли комитеты бу мәсьәләдә үзләренең бердәм икәнлекләрен тантаналы төстә белдерәләр.

Кызыл Армиянең һөҗүме туктаусыз һәм дәһшәтле көч белән дәвам итсен өчен!

Зур күтәренкелек белән

ИШЕЕВО, 6 январь. (Телефон буенча). Иптәш Сталинның котлау телеграммасы Апас районының Ишеево МТС коллективы арасында гаять зур күтәренкелек тудырды. Тракторларга ремонт ясауда эшләүче иптәшләр бу котлауны тыңлагач тагын да яхшырак эшләргә, тракторларга һәм барлык башка авыл хуҗалыгы машиналарына тик отлично билгесенә генә ремонт ясарга сүз бирделәр. Тракторларга ремонт ясауда соңгы 2-3 көннең нәтиҗәләре, тракторчыларның сүзе эштән аерылмаганлыкны ачык күрсәтте. МТС ыбыз тракторларга ремонт ясау буенча 1942 нче елның 4 нче квартал планын 145 процентка, еллык планны 75 процентка үтәде.

Тракторчылар бөек җитәкченең котлау телеграммасына стахановча эшләү белән җавап бирен, самолетлар төзү фондына үз запасларыннан средстволар туплау эшенә дә керештеләр. Бригадирлардан Н. А. Вафин һәм С. Әхмәтшин иптәшләр самолетлар төзү фондына 45 әр мең сум акча бирен, башкаларга үрнәк булдылар.

МТС коллективы тракторларга ремонт ясауны 15 нче январьдан да соңга калмый тәгәлләргә йөкләмә алды. Хәзер бу йөкләмәне шул срокта үтәү өчен тракторчылар җиң сызганып эшлиләр, көнлек нормаларны арттырып үтәми торып мастерскойдан кайтмыйлар.

ГАРИФУЛЛИН.



Арча районының «Кызыл сарай» колхозы язгы чәчүгә ныклап әзерләнә. Авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясый, орлыкларны чистарта. Колхозның тимерчесе иптәш Н. Мителев инде барлык сабаннарга һәм башка машиналарга ремонтны тәгәлләде. Рәсемдә: колхоз председателе иптәш Самат Юзеев ремонт ясалган сабаннарны тикшерә. Уңда—тимерче иптәш Мителев.

К. Тахтеев фотосы.

Средство туплау дәвам итә

ЧИСТАЙ, 6 январь. (Телефон буенча). Республикабызның колхозчыларына һәм колхозчы хатын-кызларына иптәш Сталинның җибәргән котлау телеграммасы уңае белән үткәрелгән өлкә радиомитингны Чистай районының барлык предприятиеләрендә, колхозларда һәм учреждениеләрдә күмәк рәвештә тыңладылар.

4 нче һәм 5 нче январьда барлык колхозларда да митинглар үткәрелде. Бахта авыл советына караган «Красный Октябрь» колхозы председателе иптәш Минкин самолетлар төзү фондына 10.000 сум акча бүләк итте. «Завет Ильича» колхозы членнары үз хуҗалыкларындагы запаслардан Кызыл Армия фондына 1 тонна ашлык бүләк иттеләр. Колхозчы иптәш Гарин бер центнер, колхоз председателе иптәш Боровков бер центнер, колхозчы иптәш Юданова 50 килограмм ашлык бирде. Колхозчы иптәш Минаев бер центнер ашлык бирде һәм үзенең чыгышында болай диде:

— Без Кызыл Армиябез өчен бер нәрсәбезне дә кызганмыйбыз. Без хәзер үзебезнең колхозыбызда язгы чәчүгә отлично әзерлекне тәэмин итәргә тиешбез. Бу—Кызыл Армиябез өчен зур ярдәмнәрнең берсе булачак.

Район колхозларында танклар колоннасы фондына һәм самолетлар төзүгә акча туплау, Кызыл Армия фондына ашлык тапшырулар дәвам итә.

КЫЗЫЛ АРМИЯГӘ—САМОЛЕТЛАР ҺӘМ ТАНКЛАР

Киров исемендәге колхоз (Әтнә районы) авыл хуҗалыгы эшләрен вакытында тәгәлләде. Без дәүләткә ашлык тапшыру планын үтәү йөзеннән, илебезгә 37 мең пот ашлык бирдек. Терлекчелек продуктлары буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәгәннән соң, 1943 нче ел исәбенә 50 центнер ит тапшырдык.

Сталинград фронтындагы батыр сугышчыларның зур җиңүләре бездә фронтовикларга тагын да күбрәк ярдәм итү теләген тудырды. Колхозчылар дәһшәтле сугыш кораллары төзү өчен үзләренең саклык акчаларын кертә башладылар. Бездә 5.000 сум, 10.000 сум кертүчеләрнең саны дистәләп санала. Мин үзем 20.000 сум бирдем. Шулай итеп без самолетлар төзү фондына 300.000 сум, танклар төзүгә 190.000 сум акча тупладык.

В. БАҺАВЕТДИНОВ,
колхоз председателе.

ТИМЕРЧЕЛӘР ҖАВАБЫ

КЕНӘР, 6 январь. (Телефон буенча). 4 нче январьда ВКП(б) ның Кызыл юл райкомы колхозларда эшләүче тимерчеләрнең район киңәшмәсен үткәрде. Киңәшмәдә 32 кеше катнашты. Киңәшмәдә иптәш Сталин телеграммасы укылды. Тимерчеләр телеграмманы тирәнтен рухлану белән тыңладылар. Шулай ук Сталинград янында 6 атналык сугыш йомгаклары турында Совет Информбюросы белдерүләре дә укылды.

Киңәшмәдә катнашучы барлык тимерчеләр юлбашчының телеграммасы белән рухланып, язгы чәчүне бары тик яхшы сыйфатлы итеп ремонтланган машиналар белән генә каршы алуны тәэмин итәргә сүз бирделәр, сабаннарга, культиваторларга, тырмаларга һәм башка кораллларга ремонт ясауны 1 нче февральгә тәгәлләргә йөкләмә алдылар. Тимерчесе булмаган колхозларга ярдәм оештырырга, җитешмәгән запас частьларны колхозларның үзләрендә табу һәм әзерләү чарасын күрергә, ягулык һәм ремонт материалларына экономия ясарга, ремонтның үзенә төшү бәясен 15 процентка киметергә, һәрбер тимерче үзенә алмашчы әзерләүне бурыч итеп алдылар.

Н. СИНГАТУЛЛИН.

КЫЗЫЛ АРМИЯ ФОНДЫНА

КУКМАРА, 6 январь. (Телефон буенча). Иптәш Сталинның котлау телеграммасына җавап итеп Кызыл Армия фондына «Коминтерн» колхозы председателе иптәш Әхәтов 5.000 сум акча, Разин исемендәге колхоз председателе иптәш Алексеев 10 пот ашлык һәм 10.000 сум акча, шул ук колхоз умартачысы иптәш Исаев 10 мең сум акча бүләк иттеләр.

КОЛХОЗЧЫЛАР БҮЛӘГЕ

Биектау районы колхозчылары батыр сугышчыларга күп кенә бәйрәм бүләкләре җибәрәләр. Буденный һәм Каганович исемендәге колхоз членнары 200 килограмм ит, 40 килограмм бал әзерләделәр һәм бүләкләр алу өчен 2.000 сум акча җыеп тапшырдылар. Шулай ук «Гудок», «Победа», «Смычка» колхозы членнары да батыр сугышчыларга бүләк итеп җибәрү өчен күп кенә ит, сөт, йомырка җыеп тапшырдылар.

Д. СКВОРЦОВ.

ЭКОНОМИЯ ӨЧЕН ЯРЫШ

Булган мөмкинлекләр тулы файдаланылмыйлар

Баш энергетигы иптәш Михайловский булган Н-че заводта ВКП(б) Өлкә һәм шәһәр комитетлары карарлары нигезендә ягулыкка, электр энергиясенә, парга һәм суга экономия буенча соңгы вакытларда шактый эшләр эшләнде. Мәсәлән, завод ТЭЦ ында һава җылыткычлар алыштырылды һәм ремонтланды, форсунка фронты үзгәртелде, су циркуляциясе үзгәртелде һ. б.

Бу чаралар һәр ай саен 100—130 тонна ягулыкка экономия ясарга мөмкинлек бирде. Казаннар цехының файдалы коэфициенты шактый күтәрелде. Әгәр дә 1942 елның февраль-март айларында казаннар цехының файдалы коэфициенты 0,79—0,80 булса, октябрь-ноябрь айларында инде ул 0,84—0,85 кә тигезләнде. Шуның белән бу мәсьәләдә ВКП(б) Өлкә һәм шәһәр комитетлары тарафыннан Н-че завод алдына куелган бурыч үтәлде.

Электригы иптәш Блох булган цехта экономик установка ходка җибәрелде. Бу чара участокта һәр ай саен 200—300 тонна мазутка экономия ясады. Электригы инженер Садыйков булган цехта 585 киловатт көчендәге моторларны 296 киловатт көчендәге моторлар белән алыштыру буенча зур эш башкарылды.

Начальнигы иптәш Корнилов булган цехта инженерлардан Крайный һәм Широчков иптәшләрнең тәкъдимнәре тормышка ашырыла. Алар елына 200.000 киловатт-сәгать экономия бирәчәкләр. Шулай ук ТЭЦ ка конденсатны кире кайтару күздә тотыла. Моның белән айга 200 тонна мазутка экономия ясалачак.

Ләкин шулай да Н-че заводта ягулыкка, электр энергиясенә, парга һәм суга экономия буенча барысы да эшләнә дип әйтеп булмый әле. Работниклар экономия режимы өчен көрәшкә чын мәгънәсе белән һаман да әле тотынмаганнар. Менә берничә мисал. Начальнигы иптәш Корнилов булган цех соңгы ике ай эчендә 50—60 мең киловатт-сәгать электр энергиясенә экономия ясады. Бер караганда бу күрсәткеч начар түгел. Ләкин шушы ук цехта инженер Дмитриев җитәкчелегендәге бер мастерской гына да һәр ай саен 200.000 киловатт-сәгать электр энергиясен артык тота. Бу мастерскойда электр энергиясе, барыннан да элек, электр моторларының бушка әйләнүләре исәбенә артык тотыла. Биредә мастерскойның барлык эшчеләре төшке ашка киткән вакытта да моторлар туктатылмый. Бу—электр энергиясен турыдан-туры әрәм-шәрәм итү дигән сүз.

Җылылык техникы иптәш Кукушкина булган цехта пар проводлары һәм коммуникацияләре төзек түгел. Пар проводларының изолировкасы җимерелеп төшкән, фланецлар бик нык парлана. Шуның аркасында һәр ай саен уннарча тонна пар һавага оча. Ләкин техник иптәш Кукушкина моңа чара күрү турында уйламый.

Заводта биналарны җылыту өчен җылылыкның артык тотылуы турында көн саен диярлек актлар төзелә, ләкин бу чара гына ярдәм итми. Мәсәлән, шушы көнгә кадәр иптәш Копьев җитәкчелегендәге механика цехының конторасында температура 12 градус урынына 24 градус булуында дәвам итә. Завод цехларыннан берсендә техпроп иптәш Лебедева бүлмәсендә температура 25 градуска җитә.

Ремонт-механика мастерскойларында һәм столяр-паяль цехында зур көчле моторларны аз көчле моторлар белән алыштыру эше бик акрын бара. Шуның аркасында бу цехларның көч коэфициентлары бары тик 0,5—0,4 кенә. Электриклар Грижимойло һәм Белик иптәшләр бу мәсьәләдә гафу итмәслек акрынлык күрсәтәләр.

Мондый фактларны тагын да китерергә мөмкин. Алар барысы да ягулыкка, электр энергиясенә, җылылыкка тагын да күбрәк экономия ясарга чикләнмәгән мөмкинлекләр барлыгын күрсәтәләр. Экономия режимы өчен көрәш һәркайда һәм һәрвакыт алып барылырга тиеш. Һәрнәрсәгә ныклы экономия—сугыш вакыты законы. Бу законны берсүзсез үтәргә кирәк.

Б. ОРЕШНИКОВ.

Күңелле ял

Безнең мәктәп балалары яңа елны бөек Ватан сугышы шартларында каршыладылар Шунлыктан алар мәктәптә тырышып уку белән бергә фронт турында, данлыклы партизаннар һәм ялалы сугышчылар турында кайгыртучанлык күрсәтергә кирәклекне бер генә минутка да хәтерләреннән чыгармыйлар.

Кышкы каникулларга әзерләнгән хәлдә безнең мәктәптә укучылар партизаннарга яңа ел бүләкләре алып җибәрү өчен 1.400 сум, ялалы сугышчыларга бүләк өчен 1.000 сум акча тупладылар. Үзләре чигеп күп кенә кисетлар әзерләделәр, аларга тәмәке тутырып җибәрделәр. Каникул көннәрендә балалар ялалы сугышчыларга төрле бүләкләр илтеп тапшырачаклар.

Фронтларда героик Кызыл Армиянең җиңүләре балаларның рухын тагын да күтәрде. Алар каникулларны бик күңелле итеп үткәрәчәкләр. Безнең мәктәптә укучылар өчен 70 пар чаңгы сатып алынды. Өлкән классларда укучылар шәһәр тирәсендә чаңгы походлары оештыралар. Кечерәк балалар өчен кар таулары ясалды. «Черек күл» бакчасындагы катокта коньки ярышлары булачак.

Мәктәптә елка ясалды. Шуның өстенә балалар кечкенә күчмә елкалар белән фронтовикларның балалары тора торган квартираларга һәм ялалы сугышчылар янына барачаклар. Елка янында төрлечә күңел ачулар оештырыла. Мәктәпнең үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләрендә катнашучылар җыр, музыка, бию, декламация һәм башка номерлар белән чыгышлар ясыйлар.

Каникул көннәрендә балалар бөек Ватан сугышы күргәзмәсенә һәм тарих, культура ягыннан әһәмиятле булган башка урыннарга экскурсиягә баралар. Яшь тамашачылар театрына, циркка һәм кино-театрларга культпоходлар ясала.

Бу эшләрне оештыруда күп кенә укучылар зур активлык күрсәтәләр. Отличник укучылардан Шаһиәхметов, Тамара Шишкина, Мила Куницина һәм башкалар үзешчәнлек сәнгатен оештыруда аеруча тырышып эшлиләр. 8 нче класста укучы Борис Салоп хәрби-физкультура эшләрен җайга салуда һәм чаңгылар әзерләүдә зур активлык күрсәтте. Укытучылардан К. М. Харитонова, А. М. Шургилова һәм башка иптәшләр сугышчыларга бүләкләр туплауда һәм башка җәмәгать эшләрендә һәрвакыт патриотлык үрнәкләре күрсәтәләр.

Безнең совет балалары мәктәптә тырышып укыйлар, гомуми һәм хәрби белемнәрне яхшы итеп үзләштерәләр. Шуның белән бергә алар совет гаскәрләренең җиңүләрен тәэмин итү өчен кулларыннан килгән бөтен ярдәмне күрсәтергә һәрвакыт әзер торалар. Безнең балалар, башка совет гражданнары кебек үк, 1943 нче елның җиңү елы булачагына чын күңелдән ышаналар.

А. ЕВДОКИМОВА,

Казан шәһәренең Бауман районындагы 11 нче номерлы мәктәп директоры.

ПРОМЫШЛЕННОСТЬ ӨЧЕН ЧИМАЛ

Арча сельпосының Олы Бирәзә авылындагы бүлекчәсе (мөдире иптәш Шакирҗанова) промышленностька өстәмә чимал туплауда актив эш күрсәтеп килә. Моның буенча бүлекчә үзенә тапшырылган еллык заданиене җәй айларында ук үтәп чыкты.

Хәзер иптәш Шакирҗанова промышленность өчен кирәкле һәртөрле әйберләр җыюны оештырды. Соңгы вакытта бүлекчә тарафыннан 18 данә тире, 50 данә мех, 11 килограмм яхшы сыйфатлы кош мамыгы, 80 килограмм чүпрәк, 10 килограмм резина, 2 килограмм ат кылы, шулай ук 600 килограмм кара металл, 8 килограмм төсле металл җыеп тапшырылды.

Промышленность өчен өстәмә чимал туплау дәвам итә.

НУР ХӘЙРУЛЛИН.

СЕБЕР ШАХТАЛАРЫ ӨЧЕН

Сосновка станциясенә декабрь аенда хөкүмәт заданиесе тапшырылды: Караганда шахталары өчен 170 вагон ныгытма материаллар төяргә. Станция коллективы бу заданиене срогыннан элек үтәргә йөкләмә алды. Лесоперевал комбинаты белән бергә эшләп, Сосновка станциясе работниклары үзләренең йөкләмәләрен үтәделәр — ныгытма материаллар төяү планы 19 нчы декабрьдә ук тәгәлләнде.



АФРИКАДА СУГЫШ. Рәсемдә: Англиянең беренче армиясе пулеметчиклары Матер янында (Тунис) калкулыклар арасында сугыш алып баралар.

(Лондоннан радио буенча алынган рәсем)

Совет гаскәрләренең һөҗүме турында чит ил матбугаты

«КЫЗЫЛ АРМИЯ НЕМЕЦЛАРГА ТЫН АЛЫРГА БИРМИ»

ЛОНДОН, 4 январь. (ТАСС). Англия матбугаты Кызыл Армия частьларының яңа уңышлары турындагы хәбәрләрне киң аңлатмалар белән бирә. «Таймс» газетасының хәрби күзәтүчесе, совет гаскәрләренең алты атналык һөҗүменең йомгаклары турындагы Совет Информбюросы белдерүенә кагылып, Кызыл Армия алган пленныйларның саны бик күп булуны аеруча күрсәтеп үтә.

«Ньюс кроникл» газетасының хәрби күзәтчесе майор Гриббл, Кызыл Армиянең Великие Лукины алуы турындагы хәбәргә аңлатмалар биреп, бу пунктның немецларның иң көчле каршылык күрсәтү пунктларыннан берсе булганлыгын әйтеп үтә. Шуңа күрә дә,—ди Гриббл, Великие Лукиның алынуы Кызыл Армиянең хәзерге һөҗүме барышында аның бик зур уңышы. «Великие Лукиның алынуы турындагы хәбәр барлык оккупацияләнгән илләрдә яңа рух күтәренкелеге тудыра һәм аларның тиздән азат булачакларына ышануларын ныгыта».

Кызыл Армиянең Моздокны алуына Англия радиокомментаторлары зур игътибар бирәләр. Рейтер агентлыгының хәрби күзәтчесе Фергюссон болай дип яза: «Кызыл Армиянең Моздокны алуы русларның немецлар кулыннан тартып алынган инициативадан ничек тиз һәм уңышлы файдалануларын күрсәтә. Моздок Кавказ тауларының көнчыгыш өлешендә Германия операцияләре өчен база иде».

«БҮГЕН РУСЛАР МОННАН ЭЛЕК КАЙЧАН ГЫНА БУЛГАНГА КАРАГАНДА ДА КӨЧЛЕРӘК ҺӘМ ИНИЦИТИВАЛЫРАК»

ИСТАМБУЛ, 4 январь. (ТАСС). Төркия газеталары Кызыл Армия частьлары һөҗүменең барышын киң күләмдә яктыртталар. Сталинградка килү юлларында совет гаскәрләренең алты атналык һөҗүменең йомгаклары турындагы хәбәрне Төркия газеталары барысы да урнаштырдылар. Кызыл Армия частьларының Великие Лукины һәм Элистаны алулары турындагы хәбәрләр аеруча күренекле урыннарда торалар.

Төркиянең мәгълүм журналисты Җаһид Ялчин, «Яңы Сабах» газетасында урнаштырылган мәкаләсендә, Кызыл Армиянең хәрби уңышлары немецларның мактанчык пропагандасын фаш иттеләр, ди. Аннары Ялчин болай дип яза: «Бу шәһәр немецлар тарафыннан, әлбәттә, алыначак дип белдерүе белән Гитлер Сталинградның зур стратегик әһәмияте барлыкны үзе үк әйтеп бирде. Немецлар һөҗүменең төп максаты Россиянең хәрби куәтен юк итү иде. Моннан 3—4 ай элек Геббельс, Төркия журналистларына, руслар белән барлык исәп-хисаплар якындагы ике ай эчендә өзеләчәк һәм Россия хәрби көч булудан туктылачак, дип кискен тон белән белдергән иде. Ләкин без күрәбез, немецларның әйтүенчә моннан 1—2 ай элек үк «юк ителергә» тиеш булган руслар армиясе хәзер Германия гаскәрләрен куа, аларны Сталинградтан һәм Кавказдан алып ташлый. Миллерово янында аларны кысрыклый, Котельниковоны азат итте. Димәк, немецларның планы барып чыкмады. Киресенчә, руслар инициативаны үз кулларына алдылар. Шулай итеп, немецларның вәгъдәләре берсе дә үтәлмәде. Бүген руслар моннан элек кайчан гына булганга караганда да көчлерәк һәм инициативалырак. Алар Сталинградны саклаулары белән тарихта тиңдәше булмаган уңышка ирештеләр».

ТӨНЬЯК АФРИКАДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

ЛОНДОН, 5 январь. (ТАСС). Союзникларның Төньяк Африкадагы штабы үзенең чираттагы белдерүендә, Мәҗзелбаб районында союзникларның бронетанк частьларының, җитди каршылыкка очрамыйча, разведка рейде үткәргәнлекләрен хәбәр итә. Тунис фронтының көньяк секторында да коры җир көчләре бераз активлык күрсәткәннәр. 3 нче январьда дошман авиациясе Франция позицияләрен бомбага тоткан. Шуның артыннан бу позицияләргә немецларның 30—40 танкысы катнашы белән атака ясалган. Башта дошман Франция частьларын кысрыклый алган, ләкин соңыннан французлар контрудар ясап элекке хәлне кайтарганнар.

ЛОНДОН, 5 январь. (ТАСС). «Дейли телеграф энд Морнинг пост» газетасының язуынча, Эль-Аламейн районында англичаннар һөҗүмгә күчкәннән соң 9 атна ярым эчендә Англиянең су асты көймәләре дошманның 67 транспорт пароходын һәм 12 сугыш пароходын батырганнар яки зарарлаганнар. Шуннан алдагы 42 атна эчендә Англиянең су асты көймәләренең операцияләре нәтиҗәсендә дошман 87 транспорт пароходын һәм 13 сугыш пароходын югалткан.

АНГЛИЯ АВИАЦИЯСЕНЕҢ ГЕРМАНИЯГӘ ҺӨҖҮМЕ

ЛОНДОН, 5 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгы Англия бомбардировщикларының 5 нче январьга каршы төндә Германиягә һөҗүм ясаганлыкларын хәбәр итә.

Шул ук агентлыкның икенче бер хәбәрендә Англия авиациясенең 5 нче январьга каршы төндә Рурга һөҗүм иткәнлеге әйтелә.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

— Җибутидә Франция властьлары Италиянең вакытлы килешү комиссиясенең 33 членын кулга алганнар. Алар Англиянең хәрби пленныйлар лагерена озатылганнар.

— Чех Словакиядә гитлерчылар Бенешның элекке секретаре Иржа Седмикны җәзалап үтергәннәр.

— 1943 нче елны АКШ та сугыш материаллары эшләп чыгару 1942 нче елга чагыштырганда ике тапкыр артачак. Авыр бомбардировщиклар җитештерү ике тапкыр арта. Сугыш пароходлары эшләп чыгару да бик нык артачак.

— Декабрь аенда Прагада 36 чех, шул исәптән 3 хатын-кыз җәзалап үтерелгән.

КИНО

„Райком секретаре“

Совет шәһәрләреннән берсенә немецларның һөҗүм итү эпизоды зур осталык һәм дулкынландыргыч дөреслек белән алынган. Бомбалар төшә, сирена кычкыра..: Кешеләрнең кискенлек һәм нәфрәт белән киң итеп ачылган күзләрендә ялкын һәм төтен чагыла. Бик матур яңа биналар яналар, заводларның һәм учреждениеләрнең стеналары җимереләләр.

Мәйдан. Тын гына тора торган халык төркеме. Фашистик флаглар. Аларның берсе өй түбәсенә куелган. Аны немец саклый. Автомашина өстенә күтәрелгән гитлерчы яный-яный речь сөйли. Кинәт ату тавышы. Йорт түбәсендә флаг саклап торучы немец авып төшә. Моңа җавап итеп фашистик солдатлар мәйданда торучы халыкка аталар. Кар өстенә хатын-кызлар, балалар, картлар, үсмерләр егылалар. Немец «хайль» дип кычкыра. Пулемет өзлексез ата.

Партизаннар—менә шушындый күренешләрне үз күзләре белән күргән кешеләр алар. Алар дошманга карата нәфрәт уты белән яналар. Алар нык һәм җиңелмәслек. Алар урманда, отрядка берләшкәннәр. Һәрберсе актык сулышына кадәр Ватанга турылыклы булу турында, дошманга рәхимсез булу турында ант итә. Үлемгә—үлем, канга—кан.

Немецлар партизаннардан куркалар, чөнки партизан аларны һәр урында сагалап тора. Менә фашистик ерткыч кәлә-кәлә чемоданына кыйммәтле савыт-сабалар, челтәрләр һ. б. тутыра, ләкин эшен тәмам итә алмый. Партизаннар. Бәрелеш. Фәлән кая? Үлгән. Фәлән кая? Үлгән. Фәлән кая? Үлгән. Партизаннар белән булган бәрелештән соң фашистлар әнә шундый исәп-хисап үткәрәләр.

Партизаннарны бернинди янаулар да куркыта алмыйлар. Партизаннарны «яшергән өчен» дип тыныч халыкларны асалар. —Сау булыгыз, иптәшләр, онытмагыз— дип кычкыралар алар муеннарына дар бавы салынган хәлдә. Һәм, халык арасыннан патриот аңа җавап бирә: «Беркайчан да, беркайчан да. Сезне онытмабыз!».

Партизаннар отрядына бер хыянәтче барып керә. Ул Наташа исемле кыз артыннан йөри башлый. Кыз аның хыянәтче икәнлеген ачып сала, ләкин сатлык җан партизаннар отрядының кайда икәнлеген дошманга хәбәр итеп өлгергән була. Партизаннар отрядының бер өлеше пленга эләгә, ләкин монда да партизаннар дошманнан үч алуны оста итеп оештыралар. Бик каты сугыш башлана һәм бу сугыш партизаннарның җиңүе белән тәмам була.

Бу гади, намуслы батыр рус кешеләренең—сугышка баргандә шаян сүзләр әйтеп бара торган, туган җир өчен гомерләрен бирергә әзер тора торган һәм туган җирдән берничек тә аерылмаслык һәм дошман алдында баш ими торган кешеләрнең образларын Жаров һәм Ладыгина дөрес һәм оста итеп тудыра алганнар.

«Райком секретаре» картинасы—бу сугыш вакытында тыныч кешеләр юк икәнлекне, һәрбер совет кешесенең немец өчен дәһшәт икәнлеген һәм һәрбер совет кешесенең немецтан үч алырга әзер торуын, тәмам җиңгәнгә кадәр көрәшергә әзер торуын күрсәтә торган картина.

А. ДУБИНСКАЯ.

Җаваплы редактор урынбасары **ГАЛИМ РЯБКОВ.**

Театрларда һәм киноларда

Зур драма театры. Бүген —„Тынычсыз картлык“.

Татар дәүләт академия театры. 8 нче һәм 9 нчы январьда „Мәрьям“

Яшь тамашачылар театры. Бүген көндезге 1 сәгатьтә һәм кичке 7 сәгатьтә „Иванушка һәм Гүзәл Василиса турында экият“.

Дәүләт циркы. Бүген чегән ансамле катнашы белән зур цирк тамашасы. Кич 8 сәгатьтә башлана.

„Электро“ художествolы яңа фильм — „Райком секретаре“.

„Унион“ —„Антон Иванович ачулана“.

„Пионер“ көндез — „Дуслар“, кич—„Волга-Волга“.

„Чаткы“ — „Корыч ничек чыныкты.

„Кызыл йолдыз“—„Гроза“.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 1011 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 33